**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

3 сентябрь 2019 ел №8

**Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Федераль мәгълүмат адреслы система турында” һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законнарга үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1.Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 23 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы карарына 1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.5 пунктның өченче абзацында "планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы" сүзләрен "урам-юл челтәре элементы һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда))" сүзләрнә белән алыштырырга;

б) 1.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"адресация объекты-капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгы** **Р. А. Моратов**